ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6 декабрь, 2023 ел № 28/11

2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планын (программасын) раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмә нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планын (программасын) кушымтага нигезләнеп расларга.
2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
28/11 Карарына
кушымта
6 декабрь, 2023 ел

# 2024 ЕЛГА ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ МИЛКЕН ХОСУСЫЙЛАШТЫРУ ФАРАЗ ПЛАНЫ (ПРОГРАММАСЫ)

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. 2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру фараз планы (программасы, алга таба – Фараз планы) «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) туры китереп эшләнгән.

2. 2024 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, шәһәр бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлтелгән.

3. Нигезләмәгә туры китереп, муниципаль милекне хосусыйлаштыруны законда каралган ысуллар белән башкару күздә тотыла.

## 2 бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

4. 2024 елда муниципаль казнада булган, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан максатчан кулланылмаган күчемсез милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

5. Хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез милек исемлеге:

| № т/б | Объект исеме | Урнашкан урыны | Капиталь төзелеш обьекты мәйданы/ озынлыгы | Керемнәр күләме фаразы, мең сум, 01.09.2023 күчемсез милек объектларының бәяләре мониторингы нигезендә | Фаразланган хосусыйлаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Мәләкәс елгасында причал дивары | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, «Междуречье» ТК районы | 216,6 кв. м. | | 2 квартал, 2024 ел |

6. 2024 елда үзгәртү планлаштырылган Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиеләре:

| № т/б | Предприятие исеме | Адресы | Икътисадый эшчәнлекнең төп төре | Үзгәртү |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Автомобиль юллары предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе | 423810, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Резервный юлы, 42/4, а-я 235 | Автомобиль юлларын төзү, ремонтлау һәм тоту өлкәсендәге эшчәнлек, йөк күтәрү кранын кулланып төзелеш-монтаж эшләре алып бару, автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | 100% муниципаль берәмлек өлеше белән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять |
| 2 | «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе | 423822, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспекты, 81 йорт | Муниципаль берәмлек халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча эшчәнлек | 100% муниципаль берәмлек өлеше белән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять |
| 3 | «Шәһәр коммуналь хуалыгы» муниципаль унитар предприятиесе | 423801, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Лермонтов урамы, 54 йорт | Коры җир пассажир транспорты эшчәнлеге, шәһәр һәм шәһәр янында пассажирлар йөртү | 100% муниципаль берәмлек өлеше белән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять |
| 4 | «Торак-коммуналь һәм транспорт хезмәтләре сыйфатын контрольдә тоту идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе | 423805, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Х.Туфан проспекты, 23 йорт. | Торак-коммуналь, социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны капиталь ремонтлау, реконструкцияләү һәм модернизацияләү, төзекләндерү, яшелләндерү, җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту буенча шәһәр программаларын гамәлгә ашыру өлкәсендә эшчәнлек | 100% муниципаль берәмлек өлеше белән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять |

7. 2024 елда муниципаль милектә булган акцияләрне хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

8. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/17, 2023 елның 29 мартындагы 22/11, 2023 елның 25 октябрендәге 27/10 номерлы Карары белән расланган 2022 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фараз планына (программасына) кертелгән һәм агымдагы елда хосусыйлаштырылмаган объектлар хосусыйлаштырылырга тиеш.

9. Шәһәр Советының 2022 елның 8 декабрендәге 18/10 номерлы Карары белән расланган 2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыруның

Фараз планына (программасына) кертелгән, агымдагы елда үзгәртелмәгән муниципаль унитар предприятиеләре үзгәртелергә тиеш.

10. Күчемсез милекне хосусыйлаштыру һәм хосусыйлаштыру шартлары турында, шул исәптән, милекне тартып алу белән бер үк вакытта мондый милекне сатып алучы затка сату башкарылганда, әлеге милек биләгән һәм аннан файдалану өчен зарури булган җир участогын хосусыйлаштыру шартлары турында карар Шәһәр Советы карарлары нигезендә Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

11. 2024 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез милек исемлегенә Фараз планының гамәлдәге вакытында Шәһәр Советы Карарлары нигезендә үзгәрешләр кертелергә мөмкин.